КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 16 август г.Казань № 611

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 март, 112 нче; 2008 ел, 14 апрель, 232 нче; 2009 ел, 1 июнь, 353 нче; 2010 ел, 20 апрель, 279 нчы; 2010 ел, 19 август, 667 нче; 2011 ел, 29 август, 725 нче; 2012 ел, 13 февраль, 110 нчы; 2012 ел, 25 май, 418 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, 684 нче; 2014 ел, 6 август, 572 нче; 2015 ел, 2 апрель, 211 нче; 2015 ел, 27 июль, 546 нчы; 2016 ел, 2 ноябрь, 805 нче; 2017 ел, 22 апрель, 237 нче; 2018 ел, 29 гыйнвар, 49 нчы; 2018 ел, 12 июль, 564 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 867 нче; 2019 ел, 5 ноябрь, 1014 нче; 2021 ел, 6 август, 684 нче; 2022 ел, 22 июнь, 596 нчы; 2023 ел, 28 август, 1032 нче; 2024 ел, 19 март, 159 нчы; 2025 ел, 18 гыйнвар, 22 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «җирләрдән» сүзен «җирләр составыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү турында үтенечнамә формасын;

җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составын.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы закон белән билгеләнгән срок эчендә җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәне карап тикшерә һәм кергән көненнән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты белән килештерелгән җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын (алга таба – карар проекты) яисә гариза бирүчегә мотивлаштырылган баш тарту кәгазен җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, карар проектын килештереп, җирләрнең яисә җир кишәрлекләренең сорала торган максатчан билгеләнеше расланган территориаль планлаштыру документларына һәм территорияне планлаштыру документациясенә туры килүен раслый.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында карар проекты берьюлы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән органнар белән килештерүгә, җир кишәрлеге урнашкан территориядәге җирле үзидарә органына җибәрелә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Территорияләрендә җир кишәрлеге урнашкан җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 2 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән срокларда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында карар проектын килештерүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Җирле үзидарә органы тарафыннан карар проектын килештерү җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү гамәлгә ашырыла торган объектны урнаштыру буенча башка вариантлар булмавын раслый.»;

әлеге карар белән расланган җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенечнамә формасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән башка категориягә күчерү турында үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 25 октябрь, 523 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 16 август, 611 нче
карары редакциясендә)

Форма

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрлыгы

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр
составыннан башка категориягә күчерү турында
үтенечнамә

______________________________________________________________________
(гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) яисә юридик затның атамасы)
Татарстан Республикасы ______________________________ районы территориясендә
(муниципаль район исеме)
_________________________________________________________________ ның(нең)
(җир кишәрлегенең хокук иясе исеме)
________________________________________________________________хокукындагы
(гамәлдәге хокук исеме)
______________ гектар мәйданлы, _____________________ кадастр номерлы җир кишәрлеген ________________________________________________________ өчен
(максатчан билгеләнеше)
авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан __________________________
______________________________________________________________________
(җир кишәрлеген күчерүне гамәлгә ашыру планлаштырыла торган җирләр категориясе күрсәтелә)
җирләр категориясенә күчерүне гамәлгә ашыруны сорый.

Күчерүне нигезләү:
______________________________________________________________________
(территориаль планлаштыру документларын раслау турында карар реквизитлары)
расланган территориаль планлаштыру документына туры килә;
______________________________________________________ расланган авыл хуҗалыгы
(җирләрне рекультивацияләү проекты реквизитлары)
биләмәләре җирләрен / өлешен рекультивацияләү проекты эшләнде *;
тау чикләрен бирү акты реквизитлары** _______________________________________;
җир асты байлыкларын файдалануга лицензия реквизитлары** ____________________.

*Җир кишәрлеген җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында күчергән очракта – җирләрне рекультивацияләү проекты, линия объектларын төзү чорында – авыл хуҗалыгы җирләренең бер өлешен рекультивацияләү проекты.

**Җир кишәрлеген җир асты байлыкларын файдалану максатларында күчергән очракта.

| | |
|---|---|
| Заявка бирүченең почта адресы | |
| | |
| Элемтәгә керү өчен телефон | |

Әлеге үтенечнамәгә документлар опись нигезендә теркәлә.

Заявка бирүче(ләр), ________ елның _________________ _____ номерлы ышанычнамә буенча вәкил(ләр) имзасы

____________________________________________________________/______________________
(заявка бирүченең (вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) (имза)

М.У. (булганда)

_______________________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 25 октябрь, 523 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 16 август, 611 нче
карары редакциясендә)

Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составы

1. Гариза бирүче физик затның шәхесен раслый торган документ күчермәсе.

Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (гариза бирүче индивидуаль эшмәкәрләр өчен).

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (гариза бирүче юридик затлар өчен).

2. Җир кишәрлеген авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерү турында үтенечнамә юллаган гариза бирүче исеменнән эш итәргә хокукы булган затның вәкаләтләрен раслый торган документның таныкланган күчермәсе.

3. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составыннан башка категориягә күчерелүе күздә тотыла торган җир кишәрлегенә (алга таба – җир кишәрлеген күчерү) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

4. Җир кишәрлегенә хокук иясенең җир кишәрлеген күчерүгә ризалыгы (әгәр җир кишәрлегенең хокук иясе белән мондый җир кишәрлегенә карата сервитут билгеләү турында килешү төзелгән зат булган очрактан тыш).

5. Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең күчермәсе (ул төзелгән һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукларны чикләү һәм аңа аренда рәвешендә чикләп тору турында белешмәләр булмаган очракта).

Искәрмә.

Әгәр гариза бирүче үз теләге белән документларны тапшырмаса, 1 (гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документтан тыш) һәм 3 пунктларда күрсәтелгән документлар үзләре карамагындагы дәүләт органнарыннан соратып алына.